СОВЕТ
МАТАКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Колхозная, дом 2,
село Матаки, 422473
ИНН 1617003243

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАТАК
АВЫЛ СОВЕТЫ
Колхоз урамы, 2нче йорт,
Матак авылы, 422473

Тел.: (84375) 3-81-17, 8(9372821785), факс: (84375) 3-81-18, e-mail: Matak.Drz@tatar.ru,

**с.Матаки**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
20.12. 2021ел №15/3

## Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Җир кодексы, «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 07.07.2003 елдагы 112-ФЗ номерлы Закон нигезендә, прокурор протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге Советының 25.01.2014 ел, №28/1 карары (17.12.2018, №37/3; 31.05.2021, № 9/1 редакциясендә) белән расланган "Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Матак авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә» түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) **16 статьяның 1 пунктында** «капиталь төзелеш» сүзләреннән соң «мондый рөхсәт бирү турында гариза кергән көннән алып унбиш эш көне эчендә әзерләнә»сүзләрен өстәргә:;

2) **30 статьяда:**

а) **2 пунктка** түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"6) территорияне комплексны үстерү турында Карар кабул итү.»;

б) **6 пунктта** «утыз көн» сүзләрен «егерме биш көн»сүзләренә алмаштырырга.;

3) **36 статьяның 8 пунктындагы** дүртенче абзацын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән алмаштырырга; :

«Җир асты байлыкларының аерым участокларыннан файдалану илнең оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү, җир асты байлыкларыннан

рациональ файдалану һәм саклау, әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында чикләнергә яки тыелырга мөмкин.
Территорияләрне файдалану өчен махсус шартлары булган торак пунктлар һәм зоналар территорияләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану халыкның тормыш һәм сәламәтлеге, әйләнә-тирә мохитне саклау, биналар һәм корылмаларның сакланышы, шул исәптән тау эшләнмәләренең, бораулау скважиналарының һәм җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле башка корылмаларның сакланышы куркынычын тудыра алган очракларда чикләнергә яисә тыелырга мөмкин.
Аеруча саклана торган табигый территорияләрдә җир асты байлыкларыннан файдалану аларның территорияләрен махсус саклау режимы нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Матак авылы Колхозная ур, 2йорт, Уганина пл. 27йорт; Мочали авылы Ленин ур. йорт номеры юк, Чуваш Ишли авылы Шолохова ур., йорт номеры юк урнашкан, махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Матак авыл мәдәният йорты бинасы – Уганина пл. 22 а йорты; Матак авыл җирлегенең административ бинасы,- Уганина пл. 22 а һәм Матак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән ун көн узгач үз көченә керә

Чүпрәле районы Матак
авыл җирлеге Башлыгы: В.П.Мердеев